**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.06.2019 Казан ш. № 664-п

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршындагы журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында**

«Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары Е.А.Тарнавскийга йөкләргә.

Министр в.б. Ф.Ф. Шакиров

Татарстан Республикасы
Экология һәм табигать
ресурслары министрлыгының
2019 елның «____» __________
№______ боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары
министрлыгы каршында журналистларны
аккредитацияләү кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы каршында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен регламентлый (алга таба – аккредитация, Министрлык).

1.2. Аккредитацияләү срогын чикләмичә гамәлгә ашырыла. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенең ихтыяры буенча аккредитацияләү редакциянең конкрет йөкләмәсен үтәү өчен кирәк булган вакытка яки, вакытлыча булмаган очракта, аккредитацияләнгән журналистны алмаштыру өчен (вакытлы аккредитация) башкарылырга мөмкин.

## II. Аккредитация алу хокукы

2.1. Милек формасына һәм гамәлгә куючылары составына бәйсез рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары, аккредитация үтүгә хокуклы. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узуны раслый торган документларның күчермәләре таләп ителә.

## III. Аккредитацияләү тәртибе

3.1. Аккредитацияләүгә гариза күрсәтелгән гаризаның Министрлыкка алыну фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе җитәкчесе имзасы белән Министрлыкка тапшырыла.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның вазыйфасы, кесә һәм эш телефоннары, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү

турында таныклык датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлыча аккредитацияләүгә гаризада шулай ук редакция йөкләмәсе һәм аны үтәү чоры күрсәтелә, ә аккредитация узган журналист вакытлыча булмый тору сәбәпле аны алмаштырган очракта – аны алмаштыручы журналистның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта) һәм аккредитация вакыты күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узуны раслый торган документларның күчермәләре теркәлә.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитацияләү турында (аккредитацияләүдән баш тарту турында) карар гариза кергән көннән алып ике эш көненнән соңга калмыйча Татарстан Республикасының экология һәм табигать ресурслары министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) тарафыннан кабул ителә. Мондый карар министрның тиешле боерыгы чыгарылган көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча гаризаны җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә аның редакция тарафыннан алыну фактын, датасын һәм вакытын раслау мөмкинлеген бирә торган теләсә нинди ысул белән җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсус характерда (реклама тарату, эротик басмалар) булган очракта, аккредитацияләүдән баш тартыла.

3.6. Гаризаларны карау, аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турында министр боерыгы проектын әзерләү, шулай ук кабул ителгән карар турында массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә мәгълүмат җиткерү әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокта Министрлыкның өлкән белгече (матбугат сәркатибе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә хокуклы: чарада катнашырга; чара турында Министрлык карамагында булган рәсми документларның (көн тәртибе, матбугат релизлары, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллар) күчермәләрен алырга; бастырып чыгару өчен билгеләнгән мәгълүматибелешмә материаллар белән танышырга; Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы: чара регламентын үтәргә һәм аның барышына тыкшынмаска, әгәр ул массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган булса; чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска; мәкаләләрендә (эфирдагы эшендә) матбугат релизларын, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм Министрлыктан бирелгән башка материалларны кулланганда, мәгълүмат чыганакларына сылтама ясарга; үзенең һөнәри эшчәнлеген тормышка ашырганда Министрлык эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүматларны таратмаска.

___________________________

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2019 елның 27 июнендәге 665-осн номерлы боерыгы белән расланды

## Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршында журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Кагыйдәләр «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» 1991 елның 27 декабрендәге 2124-1 номерлы Россия Федерациясе Законының 48 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы каршында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен регламентлый (алга таба – аккредитация, Министрлык).

1.2. Аккредитацияләү срогын чикләмичә гамәлгә ашырыла. Массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенең ихтыяры буенча аккредитацияләү редакциянең конкрет йөкләмәсен үтәү өчен кирәк булган вакытка яки, вакытлыча булмаган очракта, аккредитацияләнгән журналистны алмаштыру өчен (вакытлы аккредитация) башкарылырга мөмкин.

### 2. Аккредитация алу хокукы

2.1. Милек формасына һәм гамәлгә куючылары составына бәйсез рәвештә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары, аккредитация үтүгә хокуклы. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узуны раслый торган документларның күчермәләре таләп ителә.

### 3. Аккредитацияләү тәртибе

3.1. Министрлык Министрлыкның рәсми сайтында чара турында мәгълүмат урнаштыру юлы белән, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренең электрон почтасына хәбәр җибәрү юлы белән аккредитацияләү сроклары турында хәбәр итә.

3.2. Аккредитацияләүгә гариза күрсәтелгән гаризаның Министрлыкка алыну фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясе җитәкчесе имзасы белән Министрлыкка тапшырыла.

3.3. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), аның вазыйфасы, кесә һәм эш телефоннары, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чарасын теркәү турында таныклык датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлыча аккредитацияләүгә гаризада шулай ук редакция йөкләмәсе һәм аны үтәү чоры күрсәтелә, ә аккредитация узган журналист вакытлыча булмый тору сәбәпле аны алмаштырган очракта – аны алмаштыручы журналистның фамилиясе, исеме, ата исеме (булган очракта) һәм аккредитацияләү вакыты күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитация узуны раслый торган документларның күчермәләре теркәлә.

3.4. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.3 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.5. Аккредитацияләү турында (аккредитацияләүдән баш тарту турында) карар гариза кергән көннән алып ике эш көненнән соңга калмыйча Татарстан Республикасының урман хуҗалыгы министры (аның вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) тарафыннан кабул ителә. Мондый карар министрның тиешле боерыгы чыгарылган көннән башлап киләсе эш көненнән соңга калмыйча гаризаны җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә аның редакция тарафыннан алыну фактын, датасын һәм вакытын раслау мөмкинлеген бирә торган теләсә нинди ысул белән җиткерелә.

3.6. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсус характерда (реклама тарату, эротик басмалар) булган очракта, аккредитацияләүдән баш тартыла.

3.7. Гаризаларны карау, аккредитацияләү (аккредитацияләүдән баш тарту) турында министр боерыгы проектын әзерләү, шулай ук кабул ителгән карар турында массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә мәгълүмат җиткерү әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокта Министрлыкның әйдәп баручы киңәшчесе (матбугат сәркатибе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

## 4. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәгеләргә хокуклы:

чарада катнашырга;

чара турында Министрлык карамагында булган рәсми документларның (көн тәртибе, матбугат релизлары, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллар) күчермәләрен алырга;

бастырып чыгару өчен билгеләнгән мәгълүматибелешмә материаллар белән танышырга;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы:

чара регламентын үтәргә һәм аның барышына тыкшынмаска, әгәр ул массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган булса;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

мәкаләләрендә (эфирдагы эшендә) мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм Министрлыктан бирелгән башка материалларны кулланганда, мәгълүмат чыганакларына сылтама ясарга;

үзенең һөнәри эшчәнлеген тормышка ашырганда Министрлык эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүматларны таратмаска.